**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2017 елның 11 августы №90

2018-2028 елларга «ишегалды стандарты» муниципаль программасы проекты турында

Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Гыйниятовның «2018-2028 елларга «ишегалды стандарты» муниципаль программасы проекты турында» гы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, тулы канлы ял итү өчен уңайлы шартлар тудыру, даими яшәү урыны янындагы территорияләрдә халыкның югары көнкүреш культурасын формалаштыру, аның төзекләндерүдә һәм ишегалды территорияләрендә тәртип урнаштыру аша халыкның актив гражданлык позициясен формалаштыру максатыннан чыгып, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карары:**

1. 2018-2028 елларга «ишегалды стандарты» муниципаль программасы проектын килештерергә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

2.1. 2018-2028 елларга «ишегалды стандарты» программасын законнарда билгеләнгән тәртиптә 2017 елның 1 сентябренә кадәр расларга;

2.2. Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлеге белән берлектә 2018 елга программаны финанслау чыганакларын билгеләргә, алга таба программаны тормышка ашыру елларына төзәтмәләр кертергә кирәк.

3. Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының даими комиссияләренә үз утырышларында 2018-2028 елларга «ишегалды стандарты» программасының үтәлешен квартал саен карарга кирәк.

Карамалы Тау
шәһәр җирлеге
башлыгы урынбасары А.А. Абдуллин